ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 февраль, 2016 ел № 6/7

Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге 35/8 санлы Карары белән расланган Товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе 2 өлеше һәм 69 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге 35/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/9 санлы Карары редакциясендә) белән расланган Товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктның 8 пунктчасында, «сатып алулар план-графигын» сүзләре алдыннан «сатып алулар планын» сүзләрен өстәргә;

2) 7 пунктның 1 пунктчасында, «сатып алулар план-графигын» сүзләре алдыннан «сатып алулар планын» сүзләрен өстәргә;

3) 10 пунктта «сатып алулар план-графигын» сүзләре алдыннан «сатып алулар планын» сүзләрен өстәргә;

4) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Заказчы тарафыннан сатып алулар планы чираттагы финанс елына һәм планнар чорына шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары гамәлдә булу срогына туры килгән срокка формалаштырыла.

Муниципаль заказчы тарафыннан сатып алулар планы шәһәр бюджет проектын төзү һәм карау процессында формалаштырыла һәм, муниципаль заказчыга йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яки) башкаруга акчада белдерелгән хокуклар күләмен җиткергәннән соң, ун эш көне эчендә раслана.

Бюджет учреждениесе тарафыннан сатып алулар планы бюджет учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда формалаштырыла һәм, бюджет учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеген планы расланганнан соң, ун эш көне эчендә раслана.

Расланган сатып алулар планы расланган яки үзгәртелгән көннән соң өч эш көне эчендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан тыш.

Сатып алулар планы нигезендә сатып алу план-графигы чираттагы финанс елына ел саен эшләнә һәм заказчы тарафыннан, йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яки) башкаруга акчада белдерелгән хокуклар күләмен алганнан яки финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы расланганнан соң, ун эш көне эчендә раслана.»;

5) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Сатып алу планын, план-графигын формалаштырганда, планлаштырылган сатып алу заказчы тарафыннан Федераль закон нигезләмәләрен (шул исәптән Россия Федерациясе Президенты карарларын, йөкләмәләрен, күрсәтмәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, йөкләмәләрен, Россия Федерациясе субъектлары законнарын, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары йөкләмәләрен, муниципаль хокукый актларны) исәпкә алып билгеләнгән сатып алуны гамәлгә ашыру макстларына шулай ук Россия Федерациясе законнарына һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында башка норматив хокукый актларга нигезләнергә тиеш.

Сатып алу планын формалаштырганда, сатып алуны гамәлгә ашыруның Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән конкрет максатын тормышка ашыру кирәклеген һәм Федераль закон нигезендә заказчы тарафыннан сатып алынасы товарга, эшкә, хезмәт күрсәтүгә (шул исәптән товарның, эшнең, хезмәтнең чик бәясе) билгеләнгән таләпләрне, һәм (яки) дәүләт органнарының, дәүләти бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнарының, муниципаль органнарның функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны күздә тотып, сатып алу объекты һәм (яки) объектлары нигезләнергә тиеш.

План-графикны формалаштырганда нигезләнергә тиеш:

1) контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) белән төзеләсе контракт бәясе;

2) бердәнбер тәэмин итеп торучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысулы, шул исәптән сатып алуларда катнашучыларга өстәмә таләпләр.»;

6) 19 пунктның беренче абзацында «сатып алу план-графигы нигезендә» сүзләре алдыннан «сатып алулар планы» сүзләрен өстәргә;

7) 20 пунктның 3 пунктчасында «расланган» сүзеннән соң «сатып алулар планында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев